КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 7 апрель г.Казань № 367

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан тану турында» 2024 ел, 24 сентябрь, 823 нче карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан тану турында» 2024 ел, 24 сентябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 11 февраль, 68 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү

өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

7.5 пунктның беренче абзацында «субсидия алучыга субсидия бирү турында» сүзләреннән соң «яисә субсидия бирүдән баш тарту турында» сүзләрен өстәргә;

7.6 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.4 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министерлык әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацлары нигезендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару өчен нигез булган вакыйгалар ачыкланган көннән алып 30 календарь көннән артмаган срок эчендә субсидия алучыга әлеге таләп алынган көннән 10 календарь көн эчендә субсидия акчасын кире кайтару турында таләп җибәрү юлы белән субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә.»;

8.6 пунктта татар текстында «субсидияне ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләрен «субсидия акчасын ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин